Республика Татарстан
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«КЕРЛИГАЧСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»

Татарстан Республикасы
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«КИРЛЕГӘЧ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

2020 елның «03» августыннан № 14

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е КАРАР

«Кирлегәч авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
территориясендә каты коммуналь
калдыкларны туплау урыннары
(мәйданчыклары) төзүне
килештерү Тәртибен раслау
турында

Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә санитар-экологик хәлне яхшырту максатларында, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Каты коммуналь калдыкларны (мәйданнарны) туплау һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары белән «Торак урыннарны карап тотуның санитар кагыйдәләре» СанПиН 42-128-4690-88 карары нигезендә «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

«Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзүне килештерү Тәртибе;

«Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыелу урыны (мәйданы) турындагы мәгълүматларны каты коммуналь калдыклар туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү турында гариза формасы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтындагы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
" Кирлегәч авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы С.Р. Сәләхова